ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-30-61; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **КҮРСӘТМӘ**

«15 »март 2022 ел № 37-р

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы хезмәт коллективлары арасында «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексының язгы фестивален үткәрү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 30 июнендәге 1165-р күрсәтмәсе белән расланган «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексын этаплап кертү чаралары планы нигезендә:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының социаль үсеш бүлегенә 2022 елның 18 мартында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының “Олимп” спорт комплексында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы хезмәт коллективлары арасында ГТО язгы фестивален оештырырга һәм уздырырга.

2. Әгерҗе муниципаль районында «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексының язгы фестивален үткәрү турында нигезләмәне расларга (кушымта итеп бирелә).

3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Спорт мәктәбенә» МБУ «Олимп» базасында сынау-тестлар төрләре буенча судьялык әзерләүне оештыру өчен судьялар бирергә.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының МБУ «Олимпка» базада сынау-тестлар төрләре буенча судьялык әзерләүне оештыру өчен судьялар бирергә.

5. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының МБУ «Олимпка» чара өчен спорт залы, йөзү бассейны бирергә.

6. «Әгерҗе хәбәрләре» район газетасы редакциясенә ярышларның йомгаклары һәм барышы турында массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны оештырырга тәкъдим итәргә.

7. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы сайтында әлеге күрсәтмәне һәм ярышлар нәтиҗәләрен урнаштырырга.

8. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А. Баженовага йөкләргә.

**Җитәкчесе** **А.Э. Акбашев**

Татарстан Республикасы

Әгерҗе муниципаль районы

Башкарма комитеты

күрсәтмәсенә кушымта

# Әгерҗе муниципаль районында «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексының язгы фестивален үткәрү турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районынын хезмәт коллективлары арасында «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексының язгы фестивале (алга таба - Фестиваль) 2022 елда Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 30 июнендәге 1165-р күрсәтмәсе белән расланган «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексын этаплап кертү буенча чаралар планының 42 п пункты (ГТО комплексы) нигезендә уздырыла.

Фестивальне уздыруның максаты - гражданнарны системалы рәвештә, физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп итү..

Фестивальнең бурычлары:

хезмәт коллективларының физик әзерлек дәрәҗәсен күтәрү;

сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау;

- физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә мотивацияли торган шартлар;
- ГТО комплексы сынаулары (тестлары) нормативларын үтәү буенча иң яхшы нәтиҗәләр күрсәткән гражданнарны бүләкләү.

## II. Үткәрү вакыты һәм урыны

Фестиваль 2022 елнын 18 мартында “Олимп” спорт комплексында Әгерҗе шәһәре, Ометов ур., 30 йорт адресы буенча үткәрелә;

8.00-8.45 - «Олимп» СОК МБУ катнашучыларын теркәү;

8.45-9.00 - судьялар коллегиясе утырышы;

9.00-9.15 - ярышларны тантаналы ачу;

9.20 - Әгерҗе шәһәре, Ометов ур., 30 йорт, «Олимп» СОК МБУ адресы буенча нормативлар үтәү;

Нормативлар тапшырылганнан соң йомгак ясау.

## III. Катнашучыларга таләпләр һәм аларны кертү шартлары

Фестивальдә катнашырга рөхсәт ителә:

- ГТО комплексының VI-X баскычына караган 18 яшьтән 69 яшькә кадәрге гражданнарга.

- хезмәт коллективы командасы җенестән бәйсез рәвештә 10 катнашучыдан торырга тиеш;

- алдан заявкада күрсәтелмәгән гражданнар ярышларда катнашуга рөхсәт ителми (заявкага үзгәрешләр кертү очракларыннан тыш).

- Фестивальдә катнашучыларнын барысына да АИС ГТО системасында теркәлгән булырга һәм шәхси кабинетта фотография булырга тиеш.

## IV. Фестиваль Программасы

Фестиваль программасында спорт программасы да бар.

Фестивальнең спорт программасы ГТО комплексының VI-X баскычыннан тора һәм Россия Федерациясе Спорт министрлыгының 2016 елнын 12 маендагы 516 номерлы боерыгы белән расланган «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексының физкультура чараларын һәм спорт чараларын оештыру буенча методик тәкъдимнәр нигезендә формалаштырыла.

Тест-сынаулар түбәндәге төрләр буенча уздырыла:

- урыннан ике аяк белән этелеп озынлыкка сикерү (6-7 баскыч);

- гимнастик эскәмиядә туры аяклы хәлдә, алга таба иелү (6-10 баскыч);

- аркада яткан килеш гәүдәне күтәрү (6-10 баскыч);

- көч гимнастикасы:

муж. – биеклеккә тартылу (6-9 баскыч) яки 16 кг гер күтәрү (6-9 баскыч),

жен. – идәндә яткан килеш куллар белән бөгелү (6-9 баскыч) яисә тәбәнәк 90 см турникта тартылу (6-10 баскыч)

- 50 м йөзү (6-9 баскыч), 25 м йөзү (10 баскыч);

- 60 м йөгерү (6- 8 баскыч)

## V. Ярышларны уздыру шартлары

Фестивальнең спорт программасында катнашу җыелма командаларның барлык әгъзалары өчен мәҗбүри.

Ярышлар ГТО 2018 елның 01.02.2018 комплексы кысаларында халыкны тестлаштыру буенча методик тәкъдимнәр нигезендә үткәрелә. Әлеге тәкъдимнәр ГТО Бөтенроссия физкультура-спорт комплексын гамәлгә кертү һәм гамәлгә ашыру буенча Россия Федерациясе Спорт министрлыгының Координация комиссиясе утырышларында хупланган.

Ярышларда катнашучыларның барысының да спорт формасы, йөзү өчен икенче аяк киеме һәм кирәк-яраклары, индивидуаль яклау чаралары (битлек) булу.

## VI. Нәтиҗәләр ясау шартлары

Фестиваль ярышларында катнашучыларның нәтижәләре нәтиҗәләрне бәяләүнен 100 очко таблицалары нигезендә билгеләнә (2 нче кушымта Россия Федерациясе Спорт министрлыгынын 2018 елның 21 сентябрендәге 814 номерлы боерыгы белән расланган «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексынын физкультура чараларын һәм спорт чараларын оештыру буенча методик тәкъдимнәргә карата).

Ике яки күбрәк катнашучының очколар суммасы тигез булганда, өстенлекне йөзүдә иң яхшы нәтиҗәне күрсәткән катнашучы ала.

Команда зачеты ГТО комплексының яшь баскычларына туры китереп шәхси зачетта барлык катнашучылар туплаган очколар суммасы буенча билгеләнә.

## VII. Бүләкләү

Катнашучыларның командалары дипломнар һәм призлар белән бүләкләнә.

## VIII. Катнашуга гаризалар бирү

Заявкаларны 2022 елның 16 мартына кадәр agryz.gto@bk.ru электрон почтасына җибәрергә кирәк._.

**Оештыру буенча белешмәләр өчен телефоннар:**

ВФСК «ГТО» белгече

89872835112 Асатуллина Гузэл Илшатовна

ӘЛЕГЕ НИГЕЗЛӘМӘ ЯРЫШЛАРГА РӘСМИ ЧАКЫРУ БУЛЫП ТОРА.

Әгерҗе муниципаль районы хезмәт коллективлары арасында язгы фестивальдә катнашуга
ГАРИЗА

(Оешма)

| № | Ф.И.О. | Туу датасы | АИС ГТОда шәхси номер | Оешма |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |

Оешма җитәкчесе __________________________

(имза, Ф.И.О. тулысынча)